| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>БОЛЬШЕКАЙБИЦКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ОЛЫ КАЙБЫЧ<br>АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 08 июль Олы Кайбыч ав. № 8

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Кайбыч авыл җирлегенең Олы Кайбыч авылы торак пунктындагы урамнарга исем бирү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 нче елның 6 нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару Кагыйдәләрен раслау турында»гы 2014 нче елның 19 нчы ноябрендәге 1221 нче номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең карары, «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Кайбыч авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Кайбыч авыл җирлегендә яшәүчеләрнең фикерләрен һәм мәнфәгатьләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Кайбыч авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Кайбыч авыл җирлеге Олы Кайбыч авылының көньяк-көнбатышында урнашкан яңа төзелә торган урамга «Җиңү урамы» исеме бирергә.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Кайбыч авыл җирлеге рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://bkaybic-kaybici.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Җитәкче Р.Б. Сафин